| | | |
|---|---|---|
| «РАССМОТРЕНО» | «СОГЛАСОВАНО» | «УТВЕРЖДАЮ» |
| Руководитель ШМО | Зам. директора по УР | Директор МБОУ «Лашманская СОШ» |
| ____________/Минубаева М.Н./ | ____________/Зиганшина М.И./ | ____________/Нуртдинов Н.Р./ |
| Протокол №1 от «27» августа 2022 г. | «29» августа 2022 г. | Приказ № 25 от «31» августа 2022 г. |

# АДАПТИРОВАННАЯ РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

по учебному предмету «Родная (татарская) литература»
основного общего образования 8 класс
учителя I квалификационной категории
МБОУ «Лашманская СОШ»
Черемшанского муниципального района Республики Татарстан

Гайсиной Гузалии Идрисовны

**Основные документы, используемые при составлении рабочей программы:**

- Закон «Об образовании в Российской Федерации» № 273-ФЗ от 29.12.2012;
- Федеральный государственный образовательный стандарт образования обучающихся с умственной отсталостью (интеллектуальными нарушениями), утвержденный приказом Минобрнауки России от 19.12.2014 № 1599;
- Федеральный перечень учебников, рекомендуемых к использованию при реализации имеющих государственную аккредитацию образовательных программ начального общего, основного общего, среднего общего образовании (рег. 14.09.2020 № 59808);
- Закон Республики Татарстан от 22.07.2013 № 68-ЗРТ (ред. от 23.07.2014) «Об образовании»;
- Примерная адаптированная основная общеобразовательная программа для обучающихся с умственной отсталостью (интеллектуальными нарушениями), программа одобрена решением ФУМО по ОО (протокол от 22.12.2015 № 4/15);
- Основная образовательная программа основного общего образования МБОУ «Лашманская СОШ» на 2022-2023 г.;
- Учебный план МБОУ «Лашманская СОШ» на 2022-2023 г. (утв. приказом № 2 от 31.08.2022);
- Положение о рабочей программе принятой на заседании педагогического совета МБОУ «Лашманская СОШ» (протокол №1 от 29.08.2022 и утвержденного директором школы приказ № 25 от 31.08.2022)

**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

Әдәби укуны укытуның

**Төп максатлары:**

1. Укучыларны татарча аралышырга өйрәтү, лексик грамматик нигезләрен системалы рәвештә үзләштерү.

2. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү,татар теленә хөрмәт тәрбияләү,бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.

**Төп бурычлар:**

Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:
1. татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;
2. татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
3. программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
4. карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
5. татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
6. халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү

**Уку фәненең уку планында тоткан урыны**

Мәктәптә әдәбият предметы – кирәкле, әһәмиятле предметларның берсе. Ул укучыларны тормышны үзенчәлекле итеп танып белергә өйрәтә, хисси-эмоциональ дөньясын баета, эстетик зәвык тәрбияли, сөйләмен үстерә, гомумән, шәхес итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

5 нче сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:

- әдәби әсәрләрне сүзләрен дөрес әйтеп йөгерек уку;
- авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
- әдәби − теоретик төшенчәләрне рус әдәбияты белеме бе белән тәңгәлләштерү;
- татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
- авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
- 8−10 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
- 3−4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗатын турында мәгълүматлы булу;

- Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;
- төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;
- төрле халыкларның киң таралган мифларыннан хәбәрдар булу, берничә мисал китерә белү;
- 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;
- мәкаль белән әйтем, миф белән әкият, халык җыры белән автор җыры арасындагы аерманы белү;
- төрле авторларның 2–3 шигырен яттан сөйли белү;
- сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;
- төрле темаларга проект эше яклау;
- әдәби әсәрне тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

**2.Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңә белдерү;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәрләргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**Темаларның эчтәлеге.**

Язучылар китапның кеше тормышындагы роле турында. Китап бер буынның икенчесенә васыяте. Китапның төзелеше (тышы, титул, форзац битләре, астөшермәләр, бүлек исемнәре); китапны төзүчеләр (авторлары, рәссамы, редакторлары, корректоры, җыючылары, нәшрияты). Татар әдәбияты дәреслеге һәм аның белән эшләү үзенчәлекләре

«РАССМОТРЕНО»
Руководитель ШМО
______________/Минубаева М.Н./
Протокол №1 от «27» августа 2022 г.

«СОГЛАСОВАНО»
Зам. директора по УР
____________/Зиганшина М.И./
«29» августа 2022 г.

«УТВЕРЖДАЮ»
Директор МБОУ «Лашманская СОШ»
__________/Нуртдинов Н.Р./
Приказ № 25 от «31» августа 2022 г.

**КАЛЕНДАРНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ
К АДАПТИРОВАННОЙ РАБОЧЕЙ ПРОГРАММЕ**

по учебному предмету «Родная (татарская) литература»
8 класс
учителя I квалификационной категории
МБОУ «Лашманская СОШ»
Черемшанского муниципального района Республики Татарстан
Гайсиной Гузалии Идрисовны

**Календарь-тематик план**

| № | Дәрес темасы | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | план | Фактта |
| 1 | Акыллы сүзгә ни җитә! (Халык авыз иҗаты) | 1 | «Халык авыз иҗаты» схемасыбелән эш, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү | | |
| 2 | Белмәгәнгә – әкият, белгәнгә – чын (Әкиятләр) | 1 | «Әкиятләр» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә би- ремнәр эшләү, уку, сорауларга җавап бирү, җөмләләр төзү | | |
| 3 | Яхшылыкка каршы яхшылык («Ак бүре» әкияте) | 1 | Әкиятнең беренче бүлеген укып чыгу һәм терәк сораулар буенча ь анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару, тәрҗемә итү, рольләргә бүлеп уку | | |
| 4 | Яхшылыкка каршы яхшылык («Ак бүре» әкияте) | 1 | Әкиятнең икенче бүлеген уку, сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу, таблица тутыру | | |
| 5. | Яхшылыкка каршы яхшылык («Ак бүре» әкияте) | 1 | Әкиятнең өченче бүлеген уку, сораулар буенча эчтәлекне ачыклау, рольләргә бүлеп уку, иллюстрация ясау | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Булма син төлке, булырсың көлке («Абзар ясаучы Төлке» татар халык әкияте) | 1 | Эчтәлекне сорауларга җавап бирү барышында ачыклау, әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгеләү | | |
| 7 | Ана дигән хәзинә («Өч кыз» татар халык әкияте) | 1 | Текстны сәнгатьле уку, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр эшләп, әкиятнең эчтәлегенә төшенү, кызларга сыйфатнамә бирү | | |
| 8 | Д.Т.У. Яхшылык җирдә ятмый («Төлке белән Аленушка» рус халык әкияте) | 1 | Өйдә укып килгән текстның эчтәлеген сөйләү, сорауларга җавап бирү, нәтиҗә чыгару, әкият язу | | |
| 9 | Борын-борын заманда... (Кабатлау дәресе | 1 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, белемнәрне тикшерү максатыннан тест эшләү | | |
| 10 | Яшәгән, ди, булган, ди.. (К.Насыйри. «Патша белән карт» | 1 | Әңгәмә, сәнгатьле уку, рольләргә бүлеп уку, нәтиҗә ясау | | |
| 11 | Юк дип әйтмә, бардыр ул... (Г.Тукай «Су анасы» әкияте) | 1 | Әкиятне сәнгатьле уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, әкият-поэмада әкияткә хас сый- фатларны табу | | |
| 12 | Б.С.Ү. Б.Әлменов. «Су анасы» картинасы. | 1 | Рәсемне аңлау, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләү, нәтиҗә ясау | | |
| 13 | Д.Т.У. Күке сагышы (Ф.Яруллин «Хәтерсез күке») | 1 | Текстны уку, сорауларга җавапбирү, әңгәмәдә катнашу, сүзлек белән эш | | |
| 14 | Әкиятче бездә кунакта (Т.Миңнуллинның «Гафият турында әкият» әсәре) | 1. | Әкият-пьесаны сәнгатьле итеп уку, рольләргә бүлеп уку, аңла- ганны сораулар ярдәмендә тикшеү, анарлизлау | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Әкияттә кунакта («Әкият» курчак те- атры» тексты) | 1 | Яңа материалбелән танышу, укытучының кереш сүзе, укылган текст буенча фикер алышу | | |
| 16 | Әкият тә түгел, чын да түгел... (А.Тимергалин «Сәер планетада») | 1 | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу. | | |
| 17 | Әкият тә түгел, чын да түгел... (А.Тимергалин «Сәер планетада») | 1 | Хикәяне уку, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә чыгару | | |
| 18 | Әкият тә түгел, чын да түгел... (А.Тимергалин «Сәер планетада») | 1 | Хикәяне уку, образларга телдән характеристика бирү, фикер алы- шу, нәтиҗә ясау | | |
| 19 | Белем –бәхет ачкычы («Белемгә омтылу» тексты. | 1 | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү. Төрле биремнәр эшләү | | |
| 20 | Белем укудан башлана. («Мөхәммәдия» мәдрәсәсе» тексты) | 1 | Китаптагы текст белән танышу, уку, белем алу, татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, укымышлылык турында фикер алышу, укытучы тәкъдим иткән истәлекләр белән уртаклашу. | | |
| 21 | Казан университеты («Казан университеты» тексты). | 1 | Текст җөмләләрен кыскартып әйтү,сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу, төрле биремнәр эшләү | | |
| 22 | Галим кеше хөрмәткә лаек! (Г.Исхакый.«Мөгаллим) | 1 | Әсәрдән өзекне уку, сөйләү, әңгәмәдә катнашу, сорауларга җавап бирү, нәтиҗәләр чыгару | | |
| 23 | Исемдә калганнар (Г.Тукай. «Исемдә калганнар») | 1 | Текстны уку, тәрҗемә итү, укылган өлеш буенча фикер алышу, сөйләү, образларга бәяләмә бирү,сүзлек эше, би- ремнәр эшләү. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 24 | Исемдә калганнар (Г.Тукай. «Исемдә калганнар») | 1 | Текстны уку, тәрҗемә итү, ана- лиз ясау, әңгәмәдә катнашу, әсәр эчтәлеге буенча план төзү | | |
| 25 | Б.С.Ү. «Салават күпере» журналы | 1 | Хикәя төзү, диалогта катнашу, уку, сорауларга җавап бирү | | |
| 26 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» (Г.Кутуй. «Рөстәм мажаралары») | 1 | Фантастик хикәяләүне аңлап, әсәрне аңлау,сугыш чоры, пар- тизаннар турында әңгәмә кору, сүзләрне тәрҗемә итеп, мәгънәләрен аңлату. | | |
| 27 | «Әгәр мин тылсымчы булсам...» (Г.Кутуй «Рөстәм мажаралары») | 1 | Текстны уку, сорауларга җавапбирү, диалог төзүдә катнашу, эчтәлек сөйләү | | |
| 28 | Мин сине шундый сагындым.. (М.Җәлил. «Сагыну» шигыре. | 1 | Язучы иҗаты белән танышу, шагыйрьнең патриотик хистәязылган шигырьләрен искә төшерү, әсәрне укып, укытучы җитәкчелегендә бергәләп анализ- лау, нәтиҗә ясау | | |
| 29 | Гомере аның моңлы бер җыр иде... (М.Җәлил. «Соңгы җыр» шигыре). | 1 | Шигырьне уку, сорау-биремнәргә җавап эзләү, шигырьне анализлау | | |
| 30 | Кыр казы (Ф.Кәримнең «Кыр казы» шигыре | 1 | Сәнгатьле уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр аша лирик әсәрне анализлау | | |
| 31 | Сөйләр сүзләр бик күп алар... (Ф.Кәримнең «Сөйләр сүзләр бик күп алар» | 1 | Сәнгатьле уку өстендә эшләү, әңгәмә, сорауларга җавап бирү | | |
| 32 | Бәхет кайда була? (Нәби Дәүлинең «Бәхет кайда була?» шигыре) | 1 | Язучы иҗатына күзәтү ясау, әсәрен укып, ярдәмче сораулар- га нигезләнеп, аңа бәя бирү,мәкальләр белән танышу | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 33 | Туган җирдә минем бәхетем (НәбиДәүлинең «Мин җирдә калам» шигы- ре). | 1 | Шигырьне сәнгатьле уку, мәгъ нәсенә төшенү максаты белән сорауларга җавап бирү, әсәр буенча фикер алышу | | |
| 34 | Минем холкым –минем язмышым (Фатих Хөснинең «Чыбыркы» әсәре). | 1 | Укытучының сөйләвен тыңлау, әсәрне өлешләргә бүлү, анализлау. Эчтәлекнең иде- ясен әйтү | | |
| 35 | Йомгаклау дәресе. Уйныйк та көлик! | 1 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау, белемнәрне тикшерү макса- тыннан тест эшләү | | |

**Кушымта**

**Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары**

Текстны тулаем аңлап, авазларны һәм сүзләрне дөрес әйтеп, басымны дөрес куеп, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп тиешле тизлектә укыганда “5”ле куела.
Текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп, әмма 2-3 орфографик хата җибәреп(авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, синтагмаларга бүленештә ялгышу) укыганда “4”ле куела
Текстның эчтәлеген өлешчә аңлап, 4-6 тупас орфографик хата җибәреп укыганда һәм уку тизлеге акрын булганда, “3”ле куела
Текстның эчтәлеген бөтенләй аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләрне бозып, 7дән артык әйтелеш хатасы җибәреп һәм уку тизлегенә куелган таләпләрне сакламыйча укыганда, “2”ле куела.

**Диалогик сөйләмне бәяләү**

Бирелгән ситуация буенча яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, “5”ле куела.
Бирелгән ситуация яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора алганда, әмма репликаларның әйтелешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2-3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, “4”ле куела
Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4-6 хата җибәреп, эчтәлеген бозып диалогик сөйләм төзегәндә, “3”ле куела.
Бирелгән ситуация яки тема буенча диалог төзи алмаганда, “2”ле куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү:**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча әйтелеше, грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен “5”ле куела.
Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелгән, әмма аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки җөмлә төзелешендә 2-3 хатасы булган монологик сөйләм өчен “4”ле куела.
Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча эзлекле төзелмәгән, сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4-7 хатасы булган монологик сөйләм өчен “3”ле куела.
Өйрәнелгән темага яки бирелгән темага монолог төзи алмаганда, “2”ле куела

**5 нче сыйныф (рус төркеме) өчен татар әдәбиятыннан**
**арадаш аттестация эше**

**1. Добавь недостающие реплики:** *(3 балла).*

– ....
– Сәлам! Айдар, син кайсы йортта торасың?
– 24 нче йортта.
– ...?
– Мин өченче катта торам.

**2. Җөмләләрне укы, диалог төзе.** *(6 баллов).*

1) Миңа теге күлмәкне күрсәтегез әле. 2) Әйе, нинди күлмәк кирәк?
3) Ничә сум тора? 4) Ул кыйммәт түгел, 1 мең сум. 5) Сездә күлмәк бармы?

**3. *“Кинотеатрда”* дигән темага диалог төзе.** *(8 баллов).*

**<u>Бәяләү:</u>**
**“5”** ле – 17-15 балл
**“4”** ле – 14-11 балл
**“3”** ле – 10- 8 балл
**“2”** ле – 7 балл яки аннан да ким булса куела.

**5нче сыйныфта татар әдәбиятыннан арадаш аттестация эше.**
**1 вариант**

1. Әсәрләрне һәм авторны туры китерегез.
а) Л.Лерон 1) «Зөлфия...мин» ә) Ш.Галиев 2) «Пирамида»
б) А.Гыймадиев 3) «Әлләкем»
2. «Пирамида» хикәясендә нинди дәрес турында сүз бара?
Татар теле;
геометрия;
тарих.

3. Юмор ул —
драма әсәре;
көлкеле сурәтләү;
әкият нигезендә, лиро-эпик әсәр (поэма) формасында язылган арадаш (смешанный) жанр төре.
4. «Зөлфия+... мин» хикәясендә ничәнче сыйныф укучылары турында сүз бара?
Бишенче;
алтынчы;
җиденче.
5. «Зөлфия+... мин» хикәясендә малайлар
кызның портретын ясыйлар;
мәхәббәт хаты язалар;
кызга бүләк әзерлиләр;
6. «Әлләкем» шигырендә малай
китап укый;
рәсем ясый;
телевизор карый.
7. «Әлләкем» шигырендә нинди хайваннар турында язылган?
Йорт хайваннары;
кыргый хайваннар;
зоопарк хайваннары.
8. Бу елда  иң ошаган әсәр турында языгыз.
**2 вариант**
1. Әсәрләрне һәм андагы геройларны туры китерегез.
а)        «Пирамида» 1) Шәвәли ә) «Әлләкем» 2) Зөлфия
б)        «Зөлфия+...мин» 3) Мәсәлим
2. «Пирамида» хикәясендә малай нәрсәне белми?
Геометрик фигураларны;
геометрик мәсьәләне;
геометрик теореманы.
3. Юмор ул —
чәчмә әсәр;
музыкаль-драматик сәнгать жанры;
көлүнең бер формасы.
4. «Зөлфия+... мин» хикәясендә төп герой кем белән киңәшләшә?

Дусты Фәнис белән;
абыйсы белән;
әтисе белән.
5. «Зөлфия+... мин» хикәясендә вакыйга
геометрия дәресендә бара;
география дәресендә бара;
татар теле дәресендә бара.
6. «Әлләкем» шигырендә малай нәрсә ясый?
Мәче рәсеме;
эт рәсеме;
әтәч рәсеме.
7. «Әлләкем» шигырендә нинди хайваннар турында язылган?
Мәче, кәҗә, эт;
мәче, сыер, сарык;
мәче, ат, эт.
8. Бу бүлектә иң ошаган әсәрегез турында языгыз.